Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Ерсубайкино авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

08 ноябрь 2019 ел N 11

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Ерсубайкино авыл җирлегенең
Яңа Елань авылында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм алардан
файдалану мәсьәләсе буенча
халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Ерсубайкино авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ерсубайкино авыл җирлегенең Яңа Елань авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын 2019 елның 22 ноябрендәге, 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Ерсубайкино авыл җирлегенең Яңа Елань авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: җәйге бию мәйданчыгы төзелеше?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Халык җыенын Яңа Елань авыл мәдәният йорты бинасында түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Яңа Елань авылы, Үзәк урамы, 35 нче йорт.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Елань авыл башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Яңа Елань авылы, Үзәк урамы, 35 нче йорт торак пункты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Ерсубайкино
авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы В.Г.Кожуков